# ТУГАН ЯК
# РОДНОЙ КРАЙ

ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ № 14 (29) 27 ИЮЛЯ 2010




# БЕЗГӘ ГУБЕРНАТОР КИЛЕП КИТТЕ

Июль башында Матвеевка районында Ырымбур өлкә губернаторы Юрий Александрович Берг булып китте. Ул быелгы әсселек, җир чәчүчеләр өчен корылык булуын ачыклады.

Шулай ук башкалабыз хуҗасы безнең районның экономика һәм социаль үсеме турында кызыксынды. Район башлыгы Эдуард Фатыйх улы Муфазалов аңа район хәлләрен сөйләп бирде. Ю.А.Берг районда төзелеп килгән мәдәният һәм спорт объектлары белән танышты.

Очрашуда өлкәбезнең Закончыгару депутаты Ильдус Ядкәр улы Дәүләтов катнашты.

**Артур НИЗАМОВ,**
**Матвеевка районы.**

**На снимке:** Ю.Берг в Асекеевском районе осматривает поля пострадавшие от засухи.

**Фото из фотоальбома Губернатора области (портал ОГВ).**

## КҮПЛӘРНЕ КУАНДЫРАЛАР

Почта хезмәткәрләре авылда иң кирәкле һөнәрләрнең берсе диеп санала. Яңгырлы һәм карлы буран көннәрендә дә алар авыр сумкаларын күтәреп гәзит, журнал, хат, пенсия генә түгел, ә һәрбер йортка түләү квитанцияләрен дә тараталар.

Матвеевка районы Бәкер авылы хат ташучылары үзләренең эшләрен яратып, белеп эшлиләр. Почта бүлегендә Сәрия Ризатдин кызы Гиниятуллина җитәкчелек алып бара. Авыл халкы аңа газ, ут өчен түләргә керәләр. Шулай ук хат җибәрүчеләр дә аз түгел. Бу авылда халык күп гәзит, журналлар да яздырып алалар.

Шулар арасында "Туган як" гәзитен түземсезлек белән көтеп алып, бик кызыксынып укыйлар, — диеп сөйли Сәрия апа.

Ә инде Нәҗия Мәкмун кызы Минязова егерме елдан да артык хат ташучы вазыйфасын башкара. Авыл халкы бу ханымнарны яхшы эшләгәннәре өчен бик мактыйлар һәм рәхмәтләрен белдерәләр.

**Артур НИЗАМОВ,**
**Матвеевка районы.**



# БЛИСТАТЕЛЬНЫЙ МАСТЕР

В этот июльский вечер в зрительном зале Асекеевского Дома культуры наблюдался настоящий аншлаг. Были заняты даже приставные стулья. Зрителям представили концерт по итогам очередного мастер-класса Венера Хамитова. Венер — главный балетмейстер казанского театра юного зрителя, старший преподаватель гуманитарно-педагогического университета, но известен он нашим землякам как замечательный талантливый преподаватель танцев. У него мастерству учатся и стар, и млад. Причем, за считанные дни постигают не только азы этого искусства. Его питомцев впору выпускать на профессиональную сцену.

Так что, и в этот день зрители получили настоящее эстетическое наслаждение от увиденного на сцене. В нашей газете мы часто пишем про творчество Венера Хамитова и вновь можем удостоверить, что мастер нашел не только талантливых учеников, но и благодарных зрителей.

**На снимке:** Венер Хамитов.



## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЯҢА ИНТЕРНЕТ-РАДИО

"Белем.ру" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте интернет челтәрендә тагын бер яңа ресурс — "QAZAN RADIOSI" информацион-музыкаль милли интернет-радиостанциясе сайтын ясарга ярдәм итте. Әлегә радиостанцияне ачу буенча әзерлек эшләре алып барыла. Якын арада ул Казанда гына түгел, ә бөтен дөньяда сибелеп яшәгән татар халкы өчен тапшыруларын алып бара башлар, дип көтелә.

1 нче сентябрьдан алып интернет-радиостанция эфирында укытучылар һәм укучы балалар өчен татар телендә мәгариф белән бәйле тапшырулар да яңгырар, дип планлаштырыла.

Информацион технологияләр өлкәсендә үз идеяләрен тормышка ашырырга теләк белдерүчеләр "Белем.ру"ның"заказлар кабул итү бүлмәсе"нә мөрәҗәгать итә алалар.

**(Из сайта ВКТ).**

## НАСТУПАЕТ МЕСЯЦ ПОСТА

Совсем скоро, ориентировочно 11 августа, начнется месяц поста мусульман — Рамазан или Ураза. В этом году он пройдет в особенно сложных условиях для верующих. Ведь в этом месяце в дневное время суток нельзя ни есть, ни пить. Дни в августе длинные, к тому же стоят очень жаркие дни. Это будет настоящим испытанием веры.

Материал о месяце Рамазан читайте на третьей странице нашей газеты.

БЕЗДӘ ШУЛАЙ — СЕЗДӘ НИЧЕК?



8 июльдә Бөтенроссия күләмендә тугрылык, мәхәббәт һәм гаилә бәйрәме Әсәкәй район мәдәният йортында үткәрелде. Ун гаилә арасында безнең милләттәшләр дә булды. Иң күп еллар кулга-кул тотынышып, тугрылык саклап яшәгән парлар булып, Яңа Солтангол авылыннан Ядкәр һәм Сания Давлятовлар (фотода) гаиләсе булды. Аларның үткән ел кызыл-якут туйлары булды.

Бәхетле гаилә бер ул һәм кыз үстереп, хәзер дүрт оныклары белән шатланып яшиләр. Лаеклы ялда булуга карамастан Сания белән Ядкәр зур йорт-кура карап, абзар тулы мал-туар, тавык-кош, каз, үрдәк үстереп яшиләр.


Кырык елдан артык гаилә учагының җылысын балалары, оныклары һәм туган-тумачалары белән уртаклашып яшиләр Давлятовлар. Ишекләре һәрвакыт ачык, емаюлы йөз белән каршы алалар алар йортларына кергән кешеләрне.

Шулай озак еллар бергәбергә шатланып яшәгез!

**Гүзәл КАЛИМУЛЛИНА,**
**Әсәкәй районы.**

# “МӘЧЕТ СУЫ”

В это засушливое лето вода в селе Асекеево стало проблемой. Давление в трубах водопроводов большинства улиц упало или воды вовсе не бывает. В этих условиях выручает колонки по улице Комсомольской. Эта вода пользуется спросом не только у асекеевцев, но и у жителей других сел. Часто можно увидеть сельчан «затаривающих» ёмкости водой именно из этих колонок. Чистая, вкусная, ледяная — как родниковая. От одной ложки чая заваривается отличный крепкий напиток. Многие называют эту воду «мэчет суы». Видимо это связанно с тем, что рядом расположена соборная мечеть Асекеева. А может в этом и секрет особых свойств этой воды.



# ЯМЬЛЕ ҖӘЙГЕ КӨННӘРДӘ



Укучылар өчен җәйге каникуллар дәвам итә. Эссе көннәр булуга карамастан, балалар ял көннәрен бик күңелле һәм файдалы үткәрәләр. Күпләр җәйге көннәрен кунакта үткәрсәләр, башкалары мәктәптәге көндезге эш лагерьләренә сөенеп йөриләр. Матвеевка районы Иске Котлемәт авылында балалар шау-гөр килешеп ял итәләр. Мәктәптә алар өчен һәммәсе бар: ял итү бүлмәсе, телевизор, DVD, төрле уенчыклар аларның күңелләрен күтәреп, хисләндереп җибәрәләр. Ял итүдән башка, укучылар эш белән мәшгуль. Мәктәп бакчасында аллы — гөлле чәчәкләр, кыяр, помидор, кишер, кәбестә, чөгендер үстерәләр. Ә аннары авыл мәчетенә барып тирә-якны чистартып, бакчасын җыештырып та өлгерәләр. Ә инде беренче булып эшләүчеләр, авыл кырыенда урнашкан чишмәләрне җыештырып тазартканнар. Лагерь хуҗасы Светлана Рәшид кызы Хәмидуллина әйтүе буенча, балалар кызыксынып, рәхәтләнеп ял итәләр. Икенче алмашынуда барлыгы унбиш бала эшләп, күңел ачып, җәйге каникулларын үткәрәләр.

— Аш пешерүче ханымнарга да зур рәхмәт, — ди Светлана Рәшидовна. Көненә ике мәртәбә кайнар, тәмле ризыклар белән алар сыйлыйлар укучыларны. Ашамлыклар белән ЧП "Нафигова Л.Д." ярдәм итеп тора. Зур рәхмәт аңа!

Ә инде тәрбиячеләр балалар белән төрле уеннар, ярышлар еш үткәрәләр. Шушы искиткеч, җәйге матур көннәр балалар күңелендә мәңге сакланыр дигән фикердә каласы килә.

**Артур НИЗАМОВ,**
**Иске Котлемәт авылы,**
**Матвеевка районы.**

ЯКЫН ШАГЫЙРЬ

# КЫРЛАЙ — ТУКАЙ МӘКТӘБЕ

**Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл — Кырлай диләр; Җырлаганда көй өчен «тавыклары җырлай» диләр.**

Тукай — һәр татар җанлы кеше өчен бик якын шагыйрь. Аның язмышы да гади халыкныкыннан аерылмый. Әче язмыш сынауларын күп татыган Габдула, гасырларга сүнмәс йолдыз булып калды.

Быел Казанда үткәрелә торган Татар яшьләре көннәре кысаларында, миңа Тукай музеена барырга туры килде. Кырлай авылы Арча районында урнашкан, Казаннан ике сәгатькә якын юл үтәсе бар. Бу авылга якынлашкан саен, Тукайга багышланган стендлар еш очырый башлый. Ә инде Кырлай үзе бары тик Тукай белән яши.

Авылның үзәге — Тукай музее. Аның янына килгән кунакларны бөек шагыйрь үзе көтеп тора. Биредә — аның һәйкәле. Тукай музее 1960 елдан бирле эшләп килә. Иң элек ул, Кырлайның урта мәктәбе канаты астында эшли иде. 1976 елда ул дәүләт музее итеп билгеләнде. Шул ук елда И.Новоселцев Баки Урманче проектына нигезләнеп һәйкәл ясаган. Ә музей бинасы шулай ук Баки Урманче проекты белән 1979 елда төзелгән.

Музей күргәзмәләре 6 залда урнашкан. Кырлайда Тукайның шәхси әйберләре юк, алар барысы да Казанда, Шамил йортында урнашкан. Ә биредә бары тик Тукай чорындагы җиһазлар, борынгы фотолар һәм рәсемнәр.

Беренче залда безгә “Шүрәле” әсәренә нигезләнгән нәфис фильм күрсәттеләр. Икенче залда 19 гасырның кирәк-яраклары, Кырлайның борынгы фотосүрәтләрен карап була. Өченче залда — Тукайның Казанда яшәгән вакытында бастырылып чыккан китапларны күреп була. Аннан башка Казан карталары, белешмәләре белән танышып китәргә мөмкин. Һәм бу залдагы иң кызыклы экспонат — Болгар номерларыннан җиһаз. Азакы залда Тукайның хәреф җыючы булып эшләгән чагы да искә алынган.

Музейның икенче катында татар рәссамнәре иҗаты белән танышып китәргә була. Ф. Аминов кебек танылган шәхесләрнең эшләрен биредә күрсәтелгән.

Музей бинасы артында Ия елгасы ага. Суга төшә торган урынын бик матур итеп ясап куйганнар. Монда авыл малайлары су керәләр иде. Шунда башыма бер фикер килде: “Бәлки, Тукай да дуслары белән шулай елга буендагы каеннар арасында йөгереп йөргәндер”.

Җанга тагын бер сихәт: Кырлай малайларының авыз тутырып чын татар телендә сөйләшүләре! Хәзерге замандa бу бик сирәк очрый торган хәл бит!

Су буенда серле биюдә тукталып калган сыман, агачтан ясалган Шүрәлеләр әйлән — бәйләнә карша ала. Болар Баки Урманченың оста куллары эшләгән эш. Тукай әсәрләреннән илһам алып эшләнгән СТАТУЯ бу.


Ләкин, минемчә, Кырлайда иң истәлекле урын — Сәгъди абзыйның йорты. Монда Тукай кечкенә чагында яшәгән һәм монда аның “күзе ачылган”. Сәгъди йорты музейдан ерак түгел. Ләкин бу йорт авылның башка йортларыннан бер дә аерылып тормый. Хәтта аны танымыйча, узып китәргә дә мөмкин.

Сәгъди абзыйның ихатасында 19 гасырның тормыш рәвеше, көнкүреш кирәк — яраклары белән танышып уздык. Мич, сәке, бәллү, самавыр — барысы да үткән гасырларның сулышын саклый сыман. Бу йортка кергәндә үз үзеңә ышанмыйсың! "Минем аякларым Тукай баскан идәндә, Тукай йөргән җиргә баса!"

Монда туган хисләр, Тукай әсәрләрен укыганда, туган хисләргә охшаш. Кырлай үзенә генә хас бер кәеф белән яши. Аны һәр бер татар баласы татып карарга тиеш. Бу чын миллилек хисе, миллилекне сакларга ярдәм итә торган хис.

**Алсу ХАФИЗ.**

# РАМАЗАН АЕ



Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

Ураза — Аллаһы Тәгалә тарафыннан әмер ителгән гыйбадәт. Ислам диненең биш нигезе бар: 1) Иман китерү — Аллаһы Тәгаләгә ышану. 2) Намаз уку. 3) Зәкят бирү. 4) Рамазан аенда ураза тоту. 5) Хаж гыйбадәтен үтәү.

Кем уразаны инкяр кыла, бу кеше кяфер санала. Аллаһы Тәгалә моны Мөхәммәд пәйгамбәргә пәйгамбәрлек килгәннән соң ундүртенче елда, һиҗри белән икенче елда шәгъбан аенда йөкләде. Бу — адәм баласына Аллаһының олы бүләге. Ни өчен дигәндә, без ач тору белән Аллаһының рәхмәтенә ирешәбез, дөньялыкта кылган гөнаһларыбызны юабыз. Мөхәммәд галәйһи вәссәлам бу турыда болай дип әйтте: "Кем ураза тота, Аллаһы Тәгалә аның әҗер савап өмет итеп алдан кылган гөнәһларын гафу кыла". Ләкин ике төрле шарт белән: 1) Бәндә Аллаһы Тәгаләгә ышынып, ихластан гамәл кылырга тиеш; 2) Хисап. Ул адәм баласының кыямәт көнендәге хисабы. Уразаны Аллаһы Тәгаләне таныйм, кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә мине хисаплый дип торарга кирәк.

Ураза — таң беленгән вакыттан кояш баеганчыга чаклы ашаудан, эчүдән тыелып тору. Уразада ризыктан тыелып тору ният белән булырга тиеш, ягъни ураза тоту нияте булырга тиеш. Уразаның шарты шул. Ният булмаса, ураза кабул булмый.

Ураза нияте кемгә йөкләнә? Кем моны үтәмәсә, Аллаһы Тәгалә алдында җаваплы була?

Ураза гыйбәдәте, ураза тоту йөкләнә сау-сәламәт, өендә торган, балигълыкка ирешкән мөселман гакыл иясенә. Мөселман булмаган, Аллаһыга ышанмаган, кыямәт көненә ышанмаган кешегә бу гыйбадәт фарыз түгел, ул аңа йөкләнми.

Хатын-кызлар ураза тоткан вакытта хәездән һәм нифастан пакъ булырга тиешләр. Диваналарга, сабыйларга, авыруларга, мөсафирларга, хәез, нифас күрүче хатын-кызларга, бик олы яшьтәге кешеләргә, балага узган хәм бала имезүче хатын-кызларга уразага гыйбадәте йөкләнми.

Ураза тоту Ислам диненең гыйбадәте буллу сәбәпле, ул йөкләнә фәкать мөселманнарга гына, шуның өчен кяферләргә, динсезләргә, Аллаһыны инкяр итүчеләргә йөкләнми. Ләкин алар Аллаһы Тәгалә каршында җаваплылыктан азат кылынмый.

Инде диваналар турында пәйгәмбәребез Мөхәммәд әйтте: алардан акылларына килгәнчегә кадәр җаваплылык алына. Балигълыкка ирешкәнчегә кадәр сабый балалар өстенә ураза гыйбадәте йөкләнми. Үз ихтыярлары белән тотсалар ярый.

Авыруларның уразаларына карата ике караш бар. Әгәр дә авыру терелүгә өметсез булса, ул кеше Фидия генә бирә, бурычын тотмый, каза кылмый. Авыру төзәлүгә өметле булган очракта, ураза тотып, әҗерен кайтара.

Бик олы яшьтәге кешеләргә ураза тотарга мөмкинчелек булмаса, фидия бирә (мескен, фәкыйрьләрне ашата).

Мөсафирларга Аллаһы Тәгалә җиңеллек бирде. Алар уразаларын юлда тотмыйлар, илләренә, ватаннарына кайткач уразасын көнгә-көн кылалар.

Хәез һәм нифас хәлендә булган хатын-кызларга карата алар пакъләнгәч кенә уразаларын тоталар, калган көннәрен каза кылалар, көнгә-көн кайтаралар. Хәез һәм нифас вакытында ураза тотсалар, ул кабул булмый.

Бала имезүче, балага узган хатын-кызларга ураза тоту зыян китерсә, алар уразаларын башка вакытта көнгә-көн тоталар.

Кайсыбер вакытта ураза тотучылар сәхергә тормыйча йоклап калалар. Йокыдан torгач, уразагызга ният кылырга кирәк, әгәр кояш баегач кына ашасагыз, уразагыз кабул кылыначак. Тик шуны истә тотарга кирәк, сәхәр вакытында ашавыбыз Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән нигъмәте, хөрмәте, без аннан файдаланырга тиешбез. Пәйгамбәребез әйтте: "Сәхәрдә бәрәкәт", — диде. Сәхәрнең вакыты төннең яртысыннан алып таң беленгәнчегә кадәр, ягъни кояш чыгарга сәгать ярым кала.

Таң беленгәннән алып, кояш батканчыга кадәр ашамыйча, эчмичә ач торуыбыз, аның алдыннан ният кылу шартын үтәү — бу безнең ураза тотуыбыз. Инде кем исеннән чыгарып, максат итмичә ялгыш ашаса йә эчеп җибәрсә, уразасын өзмичә тәмамлый, аның уразасы уразадан санала. Бу Пәйгәмбәребезнең әмере.

Кем ураза вакытында үзе теләмичә коса, уразасы бозылмый.

Кояш баеганчыга кадәр хатын-кызның нифас яисә хәезе килсә, уразасы бозыла, хәттә кояш баерга бер минут калса да.

Кадерле дин кардәшләр! Ураза тоту таң беленүдән кичке кояш алынуга кадәр ашауэчүдән саклану гына тугел. Ураза — ул начар сүзләрдән, бозык гамәлләрдән саклану да. Чөнки әшәке сүзләр сөйләүченең, начар гамәлләр кылучының уразасы Аллаһы раббыбызга кирәкми. Аллаһы Тәгалә күңелләребезгә узенең рәхмәтен салып, ураза вакытларында теләребез яхшы сүзләр генә сөйләсен, эшләгән гамәлләребез әҗерле-саваплы гына булсын иде, ярабби. Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә хозурында басып торган вакытларыбызда, дөнья мәшәкатьләрен калдырып тоткан уразаларыбыз, кылган догаларыбыз, хәерле гамәлләребез безгә шәфәгатьче һәм шәкәкъ булсалар иде. Аллаһының рәхмәтенә, җиннәткә юлларыбыз ачык булса иде. Һәрберебезнең иманы бу авыр заманда, мәшәкатьле вакытында нык, туры булып, безнең дин юлында яшәвебезне саклап калса иде.

Рамазан аенда мөселманнарга аерым бер бүләк бирде Аллаһы Тәгалә. Бу — Кадер кичәсе. Пәйгәмбәребез: "Кадер кичендә сөйләгән сүзләребезнең әҗере башка вакыттагы мең айдан да күбрәктер", — диде. Уразаларыбыз мөбәрәк булсын!

# АНКЕТА “ТУГАН ЯК”

**Безнең өчен һәрберегезнең фикере бик мөһим!**
**Түбәндәге сорауларга җавапларыгызны төркәп, безгә җибәрегез.**
**Заполненную анкету высылайте по адресу: с.Асекеево, Чапаева, 24.**
**Редакция газеты “Туган як — Родной край”**
**Нам очень важно Ваше мнение.**

ИСЕМЕГЕЗ (ИМЯ)

КОНТАКТЛАРЫГЫЗ (КОНТАКТЫ)

ЯШЕГЕЗ (ВОЗРАСТ)

СЕЗ (ВЫ):
УКЫЙСЫЗ (УЧИТЕСЬ)
ЭШЛИСЕЗ (РАБОТАЕТЕ)
ПЕНСИЯДӘ (НА ПЕНСИИ)

“ТУГАН ЯК”ТА КАЙСЫ ТЕМАЛАРГА ЯЗЫЛГАН МӘКАЛӘЛӘРНЕ КҮРӘСЕГЕЗ КИЛӘ? (МАТЕРИАЛЫ НА КАКИЕ ТЕМЫ ВЫ ХОТЕЛИ БЫ УВИДЕТЬ В ГАЗЕТЕ “ТУГАН ЯК”)

ТАНЫЛГАН ШӘХЕСЛӘР БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ (ИНТЕРВЬЮ С ИЗВЕСТНЫМИ ЛИЧНОСТЯМИ)

ГАДИ КЕШЕЛӘР ТАРИХЛАРЫ (ИСТОРИИ ИЗ ЖИЗНИ ПРОСТЫХ ЛЮДЕЙ, ЗЕМЛЯКОВ)

ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘР (ЛИТЕРАТУРНЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ ТАТАРСКИХ ПИСАТЕЛЕЙ)

БАШКАЛАРЫ (ДРУГИЕ)

ТАГЫН НИНДИ ГАЗЕТАЛАРНЫ УКЫЙСЫЗ? (КАКИЕ ГАЗЕТЫ ЧИТАЕТЕ?)




**«Туган як» — газета твоего родного края!**

Продолжается подписка на татарскую культурно-просветительскую газету северо-запада Оренбургской области «Туган як. Родной край» с доставкой со следующего месяца.

Газета распространяется в Асекеевском, Бугурусланском, Абдулинском, Северном, Матвеевском и Пономаревском районах. Материалы публикуются на татарском и русском языках.

Подписаться можно в любом почтовом отделении или непосредственно у почтальонов.

Индекс издания 53167.

Цена символическая.

Справочные телефоны в Асекеево: **8-(353-51) 2-22-81.**

# ТЕКСТЫ ПОПУЛЯРНЫХ ТАТАРСКИХ ПЕСЕН

## УФТАНМА

Уфтанма, гомерләр
яз кебек үтә, дип,
Чал чәчең күрсәң дә, уфтанма.
Яз килә дә китә, гомер шулай үтә,
Уфтанма, уфтанма, уфтанма.

Уфтанма, бит синең ул узган гомерең
Уйнап, көлеп кенә үтмәгән.
Сиңа насыйп булган ак бәхет —
зур шатлык,
Якты көн әле бит бетмәгән.

## АГЫЙДЕЛ КАТЫ АГА

Агыйделдә йөрсәң иде,
Камыштан көймә үреп;
Былбыл булып, гөлгә кунып,
Сөйләшсәң иде күреп.

Агыйдел буенда
Җәяү йөрисем килә;
Сөя микән, сөйми микән,
Шуны беләсем килә.

Аклы күлмәк җиңе тар,
Җиң очында хаты бар;
Хатын укып карагачтын —
Сөям дигән сүзе бар.

Агыйдел күпере,
Чуенмы әллә чылтырый;
Каш астында ике күзе
Энҗе кебек елтырый.

Агыйделдән көймә килә
Кылдай нечкә эз белән;
Җаным, нигә хәтрең калды
Уйнап әйткән сүз белән?!

Агыйдел буенда
Җәяү йөрисем килә;
Сөя микән, сөйми микән,
Шуны беләсем килә.

## МӘК ЧӘЧӘГЕ

Мәк чәчәген өздем ялгыш кына,
Чүп үләне белән бутадым.
Мәк чәчәген, белми киләчәген,
Үз кулларым белән утадым.

Мәк чәчәген өздем ялгыш кына,
Күз яшьләре түктең син шуңа.
Чәчәкләргә багышлаган гомерең
Тукталган күк булды юлыңда.

Мәк чәчәген өздем ялгыш кына,
Шиңгән чәчәк яшәрмәс инде;
Вакыт үтәр, күз яшең дә кибәр,
Бәлки, гафу итәрсең мине.



# ОБЪЯВЛЕНИЯ

Редакция газеты «Туган як. Родной край» готова на взаимовыгодных условиях **сотрудничать** с **рекламодателями** и по их заказу готовить и публиковать тематические статьи и материалы.

**Уважаемые подписчики газеты!** Редакция принимает заявки на публикацию поздравлений, благодарностей и объявлений, в том числе и на татарском языке. Так как газета выходит два раза в месяц, просим делать заявки заблаговременно. Справки по телефонам **8 (353-51) 2-22-81.**

Редакция «Туган як. Родной край» с благодарностью **примет спонсорскую помощь** от организаций и частных лиц для издания газеты. Справки о банковских реквизитах по телефонам **8 (35351) 2-22-81.**

## ПРОГНОЗ ПОГОДЫ

**27 ИЮЛЯ, ВТОРНИК**
Ночью +22. Днем +35.
Облачно. Без осадков.

**28 ИЮЛЯ, СРЕДА**
Ночью +23. Днем +35.
Ясно. Без осадков.

**29 ИЮЛЯ, ЧЕТВЕРГ**
Ночью +23.Днем +35.
Облачно. Без осадков

**30 ИЮЛЯ, ПЯТНИЦА**
Ночью +22. Днем +35.
Ясно. Без осадков

**31 ИЮЛЯ, СУББОТА**
Ночью +22. Днем +37.
Ясно. Без осадков

**1 АВГУСТА, ВОСКРЕСЕНЬЕ**
Ночью +25. Днем +36.
Ясно. Без осадков.

**2 АВГУСТА, ПОНЕДЕЛЬНИК**
Ночью +21. Днем +36.
Ясно Без осадков.

**3 АВГУСТА, ВТОРНИК**
Ночью +21. Днем +34.
Ясно. Без осадков

**4 АВГУСТА, СРЕДА**
Ночью +19. Днем +31.
Облачно. Без осадков



## ПРОГРАММА ТНВ ТАТАРСТАН
ВРЕМЯ МЕСТНОЕ

### ВТОРНИК 27 ИЮЛЯ

08-00 Жанлы дустым баяным
10-00 Доброе утро!
11-00 Покушение. (6-я серия)
12-00 Жырлыйк эле
13-00 ТВ фондыннан
13-30 Халкым минем...
14-00 Эдера. (26-я серия)
15-00 Один день из жизни войны
15-30 Естественная красота
16-00 Новости Татарстана
16-15 Хочу мультфильм!
16-30 Кучтэнэч
16-45 Яшьлэр тукталышы
17-15 Классная работа
17-30 Авыл эте Акбай. (3-я серия)
17-55 Музыкаль NON-STOP
18-10 Приключения швейцарской семьи Робинсонов
18-45 Татарстан хэбэрлэре
19-00 Эдера. (27-я серия)
20-00 Кучтэнэч [ТНВ]
20-15 Хочу мультфильм!
20-30 Новости Татарстана
21-00 Сокровища Дамаска. (2-я серия)
22-00 Татарстан хэбэрлэре
22-30 Туган жир
23-00 Кучтэнэч
23-15 Хочу мультфильм!
23-30 Новости Татарстана
00-00 Покушение. (6-я серия)
01-00 Шарп. (1-я серия)
02-00 Автомобиль
02-30 Сокровища Дамаска. (2-я серия)
03-20 Шэфкать. (2-я серия)
04-10 ТВ фондыннан
04-40 Жырлыйк эле
05-25 И вальс, и милонга

### СРЕДА 28 ИЮЛЯ

08-00 Моннарымны сезгэ тапшырам
09-00 Жырлы гаилэ
10-00 Доброе утро!
11-00 Покушение. (7-я серия)
12-00 Ватандашлар
12-30 Очрашу шатлыклары
13-00 Китап
13-30 Яшьсен театр!
14-00 Эдера. (27-я серия)
15-00 Среда обитания
15-30 Естественная красота
16-00 Новости Татарстана
16-15 Хочу мультфильм!
16-30 Кучтэнэч
16-45 Син — минеке, мин — синеке
17-15 Авыл эте Акбай. (4-я серия)
17-55 Музыкаль тэнэфес
18-10 Приключения швейцарской семьи Робинсонов. (18-я серия)
18-45 Татарстан хэбэрлэре
19-00 Эдера. (28-я серия)
20-00 Кучтэнэч
20-15 Хочу мультфильм!
20-30 Новости Татарстана
21-00 Сокровища Дамаска. (3-я серия)
22-00 Татарстан хэбэрлэре
22-30 Кара-каршы
23-00 Кучтэнэч
23-15 Хочу мультфильм!
23-30 Новости Татарстана
00-05 Покушение. (7-я серия)
01-00 Шарп. (2-я серия)
02-00 Видеоспорт
02-30 Сокровища Дамаска. (3-я серия)
03-20 Шэфкать. (3-я серия)
04-10 Син — минеке, мин — синеке
04-40 Китап
05-05 Концерт. (Классическая гитара в XXI веке)

### ЧЕТВЕРГ 29 ИЮЛЯ

08-00 Жаным тулы музыка
10-00 Доброе утро!
11-00 Покушение. (8-я серия)
12-00 Кэеф ничек?
13-00 Сэхнэ моннары
13-30 Туган жир
14-00 Эдера. (28-я серия)
15-00 Соотечественники
15-30 Естественная красота
16-00 Новости Татарстана
16-15 Хочу мультфильм!
16-30 Кучтэнэч
16-45 Мэктэп
17-00 Авыл эте Акбай. (6-я серия)
17-55 Музыкаль NON-STOP
18-10 Приключения швейцарской семьи Робинсонов. (19-я серия)
18-45 Татарстан хэбэрлэре
19-00 Эдера. (29-я серия)
20-00 Кучтэнэч
20-15 Хочу мультфильм!
20-30 Новости Татарстана
21-00 Сокровища Дамаска. (4-я серия)
22-00 Татарстан хэбэрлэре
22-30 Татарлар
23-00 Кучтэнэч
23-15 Хочу мультфильм!
23-30 Новости Татарстана
00-00 Покушение. (8-я серия)
01-00 Шарп. (3-я серия)
02-00 Видеоспорт
02-30 Сокровища Дамаска. (4-я серия)
03-20 Шэфкать. (4-я серия)
04-10 Жаным тулы музыка

### ПЯТНИЦА 30 ИЮЛЯ

07-50 Жомга вэгазе
08-00 Китмэ, сандугач...
09-00 Пар чишмэ
09-50 Актуальный ислам
10-00 Доброе утро!
11-00 Ойлэну
13-20 Жомга вэгазе
13-30 Нэсыйхэт
14-00 Эдера. (29-я серия)
15-00 Реквизиты былой суеты
15-15 НЭП
15-30 Естественная красота
16-00 Новости Татарстана
16-15 Хочу мультфильм!
16-30 Кучтэнэч
16-45 Мультфильм
17-00 Авыл эте Акбай. (8-я серия)
17-55 Музыкаль тэнэфес
18-10 Приключения швейцарской семьи Робинсонов. (20-я серия)
18-45 Татарстан хэбэрлэре
19-00 Эдера. (30-я серия)
20-00 Кучтэнэч
20-15 Хочу мультфильм!
20-30 Новости Татарстана
21-00 Тайна Черного моря
22-00 Татарстан хэбэрлэре
22-30 Адам белэн Хэва
23-00 Кучтэнэч
23-15 Хочу мультфильм!
23-30 Новости Татарстана
00-00 Так и будет
02-30 Джазовый перекресток
03-00 Шпионские страсти
04-30 Алдым — бирдем

### СУББОТА 31 ИЮЛЯ

08-00 Татарстан хэбэрлэре
08-15 Новости Татарстана
08-45 Путь
09-00 Сина Миннэн Sэлам
11-00 Мультфильмы
11-30 Алиса в Стране Чудес. (1-я и 2-я серии)
13-00 Мужское дело
13-30 Видеоспорт
14-00 Татар халык жырлары
14-30 Яшэсен театр!
15-00 Ач, шигърият, серлэренне
15-15 Сунгэн йолдызлар
17-20 Син жырлаган чакта
18-00 Канун. Парламент. Жэмгыять
18-30 Профсоюз — союз сильных
18-40 Секреты татарской кухни
19-00 КВН-2010
20-00 Мультфильмы
20-30 Один день из жизни войны
21-00 Среда обитания
21-30 Оныта алмыйм..
22-00 Татарстан. Атналык кузэту
22-30 Жырлыйк эле!
23-15 Елмай!
23-30 Новости Татарстана. В субботу вечером
00-00 Жандарм на отдыхе
01-40 Бои по правилам TNA на Кубок «TATNEFT»
02-10 Ночной музыкальный канал
04-00 Как убить собаку вашего соседа
05-40 Татар халык жырлары

### ВОСКРЕСЕНЬЕ 1 АВГУСТА

08-00 Новости Татарстана. В субботу вечером
08-30 Татарстан. Атналык кузэту
09-00 Ретро-концерт. (Аулак ой)
11-00 Секреты татарской кухни
11-30 Музыкаль тэнэфес
11-45 Мэктэп
12-00 Тамчы-шоу
12-30 Яшьлэр тукталышы
13-00 Грани «Рубина»
13-30 Автомобиль
14-00 Ватандашлар
14-30 Татарлар
15-00 Татар халык жырлары
15-30 Мэдэният доньясында
16-40 Признание в любви — мэхэббэткэ мэдхия
18-40 Мужское дело
19-00 Путешествие со вкусом. (9-я и 10-я серии)
20-00 Мультфильм
20-10 Жандарм на отдыхе
22-00 Кэеф ничек?
22-45 Дорога без опасности
23-00 Шпионские страсти
00-40 Видеоспорт
01-10 Ворошиловский стрелок
02-50 Сегодня ты умрешь
04-20 Ватандашлар
04-45 Елмай!


ТУГАН ЯК
РОДНОЙ КРАЙ

**E-MAIL:**tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

**УЧРЕДИТЕЛЬ:**
ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:**
С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском, Северном районах. Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

Редакция не всегда разделяет мнение авторов газеты

ГАЗЕТА ОТПЕЧАТАНА В БУГУРУСЛАНСКОЙ ТИПОГРАФИИ.
461600, г.Бугуруслан, ул.Революционная, 14.
Цена свободная.ТИРАЖ: 1001 ЭКЗ.

**Редколлегия**